
# Р Харис шигырьләрендә тел-сурәтләү чаралары. Йомгаклау дәресе.



***Ренат  Мәгъсүм улы Харис:***
***Үземнең бар тырышканым***
***чын Кеше булу…***



***Ренат Харис әдәбиятка 60 нчы еллар башында Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, Р. Мингалим, Р.Гатауллиннар белән бер дулкында килә. Бу дәвердә әдәбиятка, сәнгатькә беркадәр иреклек бирелә, күп еллар дәвамында изелеп, кысылып яшәгән шигъри сүз, азатлык җилләренә битен куеп, халык күңеленә, рухына якыная төшә. Язучы фикерен өздереп, кичерешен иректә калыпка салып бирү мөмкинлеген ала.***



***Сынландыру, янәшә кую, бер күренешнең мәгънәсен икенчесеннән табу, өченчесе ярдәмендә ачу – Р.Харисның фикерләү үзенчәлеге. Шул алымнар ярдәмендә шагыйрь кешенең рухи халәтен ача, шәхеснең чын-барлык белән мөнәсәбәте катлаулы һәм каршылыклы булуын күрсәтә.***

***Шигъриятенең бу сыйфатлары "Дөньям кызыксындырса...", "Яфрак", "Көтелмәгән көн", "Чын җылы чак җитте исә" кебек шигъри бәйләмнәрендә ачык төсмерләнә.***

***"Сабантуй", "Йола", "Ак сөлге" шигырь-ләрендә ул татар халкының милли йолалары, кабатланмас үзенчәлекләре турында уйлана, һәр күренештә эчке мәгънә таба***

Нинди сыйфат үзенчәлекләре белән Р.Харис замандашларыннан аерылып тора?

**Р.Харисның иҗаты өчен кешенең фикерләү рәвешенә, уйлану дөньясына үтеп керүгә омтылыш хас. Ул – шарт-лаулы, көтелмәгән алымнар, кыю метафоралар шагыйре. Лирик герое көчле - нык ихтыярлы шәхес. Аның каләме тудырган Мулланур Вахитов, Муса Җәлил, Фатих Кәрим кебек тарихи шәхесләр образлары шуңа мисал**

## Р.Харис иҗатының төп темалары:

1. Шагыйрьнең күпчелек әсәрләре туган илгә, аның ямьле табигатен, шул хозурлыкның бердәнбер хуҗасы – кешене олылауга багышланган. Шагыйрь хисенең нигезендә туган илнең мәңгелегенә иман, ышаныч ята.
2. Р.Харисның татар халкына, аның тарихына, аның ачы язмышына багышлап язылган шигырьләре бик күп. «Җил», «Сәйях», «Татар иле», «Татар бәйрәме», «Төрки телләр» шигырьләре шундыйлардан. Бу шигырьләрне укыганнан соң үз халкың өчен горурлык тойгылары кичерәсең.


***.3. Кеше һәм табигать, аларның үзара мөнәсәбәте дә – Р.Харис иҗатындагы төп темаларның берсе. «Яфракларың гәрәбә...», «Коела яшел яфрак», «Җир – чәчәк», – дигәч...», «Яктылык төшә», «Өянке» һ.б. әсәрләрендә табигатьтә җәмгыять өчен, кешеләр өчен гыйбрәтле хәлләрне күп таба әдип.***

***4. Шагыйрьнең халык әхлагында, аның көнкүрешендә, гадәт-йолаларындагы якты якларга багышланган әсәрләре: «Сабантуй», «Чулпы», «Ак сөлге» шигырьләре. «Ак сөлге» – күчерелмә мәгънәдә кешенең тормыш-күңелен күрсәтә.***

***Ренат Харис иҗатының идеясе: «Кешеләрнең күңеле «ак сөлге» кебек чиста булсын!».***

***Шагыйрь әсәрләренең лирик каһар-маны Җирнең иминлеге, халыкларның, милләтләрнең хөр яшәве турында кайгыртып уйлана, дөньяның, табигатьнең, КҮҢЕЛ МАТУРЛЫГЫН күреп соклана һәм ул матурлыкның мәңге дәвам итәчәгенә зур өмет баглый, аны сакларга, аның кадерен белергә чакыра.***

*“Матурлык хисе тәрбияләү, ләззәт бирү, уйлату, фикер уяту, яратырга һәм нәфрәтләнергә өйрәтү кебек мәңгелек проблемаларга чишелеш эзләүдә поэзияне иң тәэсирле рухи көч дип танырга була. Поэзиянең эчтәлеге гармония турында сөйләү түгел, поэзия ул – үзе гармония”, - дип саный Р.Харис.*



***Шагыйрь күп шигырьләрендә үз халкының вәкаләтле илчесе булып фикер йөртә. Ул – халыкның нәрсәгә бай, нәрсәгә мохтаҗ булуын ачык төшенә, йөрәге белән кичерә***

***Шагыйрь үзенең шигырь, поэма-ларында һәм күпсанлы әдәби тәнкыйть әсәрләрендә татар халкының тарихи яшәеше, КЕШЕ ШӘХЕСЕНЕҢ ТОРМЫШТАГЫ УРЫНЫ, аның табигать, җәмгыять, хакимият белән мөнәсәбәте, буыннар дәвамлылыгы турында уйлана, заманның ӘХЛАКЫЙ, РУХИ, иҗтимагый күренешләренә үзенең фәлсәфи һәм гражданлык карашын белдерә***

*Р.Харис – кырыктан артык поэма, дистәгә якын шигъри цикллар, йөз илледән артык җыр, романслар, кантаталар, ораторияләр авторы. Ул – композитор М.Яруллин белән берлектә татар милли сәнгатендә оратория жанрына нигез салучы. Аның поэмалары буенча опералар («Идегәй», Р. Гобәйдуллин; «Тукай мәхәббәте», Р.Ахиярова) языла, балет («Йосыф кыйссасы», Л.Любовский) куела, телефильмнар («Камил Якуб», «Сәйдәш яры», «Шашкын мәхәббәт») экранлаштырыла, эфирда радиоспектакльләр («Сабантуй», «Гармунчы», «Чехов базары», «Бүре күзе», «Худяков») яңгырый. Шагыйрьнең «Серле алан» әсәре курчак театрлары өчен иң яхшы татар пьесалары антологиясендә урын ала. Р.Харис сценариесе буенча Г.Тукайга багышланган «Озари мне душу песней» исемле музыкаль кинофильмы куела, республика тормышына нисбәтле «Дорога на Сабантуй» дигән документаль фильм дөнья күрә.*

*Р.Харис – Бөтендөнья татар конгрессы һәм Ф.Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале идеяләре авторы.*

**Синдә бармы бу сыйфатлар?**

**Игелеклелек,**

**эшчәнлек, файдалы булу**

**Көчле рухлы, тормышны ярата, түзем**

**Изге күңеллелек, сабырлык**

**Нечкә күңеллелек**

**Изге күңеллелек, хөрмәт, ярату**

**Тугрылык**

**Яхшылык, изгелек**

**Рәхимлелек**

**Бер-береңә игътибарлы булу**

# Сораулар.

**1** Р.Харис белән бергә татар шигъриятенә килгән шагыйрьләр кемнәр?
А М.Җәлил,А.Алиш,Г Кутуй.
Б Х.ТҖуфан,И.Сәләхов,Г.Ибраһимов.
В Р.Фәйзуллин,Рәдиф Гатауллин,Р.Мингалим.
**2** Иҗатының төп темалары
А.Мәхәббәт,
Б. Сугыш чоры кешеләренең сагышы
В. Табигать образы аша кеше кичерешләрен тасвирлау

**3**.Бу  шигырьләр кайсылары Р Харисныкы?

А “Туган тел”,”Гали белән кәҗә”  “Көз”

Б “Җырларым”,”Төрмә”,”Дустым”

В. ”Ак сөлге”,”Өянке”,”Җир чәчәк”.

**4.**Р Харис иҗат иткән әдәби төрләр?

В.Музыкаль комедия,лирик комедия

Б. Юлъязма,тарихи роман.

В. Публицистик лирика,поэма.

**5.**Р.Харисның туган ягы

А. Арча ягы

Б .Буа

В. Мөслим.

# Җаваплар.

1. В.
2 .В
3. В
4. В.
5. Б

**Риторик сорау, риторик өндәү, риторик эндәш** – лирик геройның укучыга, әсәрдә сурәтләнгән образга эндәшүе.

**Метонимия** – бер күренеш, әйбер, кешегә хас сыйфат, билге белән атау ярдәмендә барлыкка килә торган сурәтләү чарасы.

Метафоралар -мәгънәне көчереп кую, яшерен чагыштыру.

**Чагыштыру** – нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы

**Сынландыру** – җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтү.

**Инверсия** – сүзләрне сөйләмдәге гадәти тәртибен үзгәртү ярдәмендә яңа эмоциональ төсмер бирү